АТАСЫ БЕЛӘН МАЛАЕ

Улы мәктәптән кайтып кергәч, атасы аннан:
- Йә әле, Фәрит, әйт әле, нинә "ике"лең бар? - дип сорагач. Фәрит әйткән:
- Һи, әти, ир кешеләр вакланып юк-бар турында сөйләшеп маташмыйлар инде.



Бер атна, ике, өч, бер ай, ниһаять, ай ярым дигәндә...
2 нче бит.

Таныш булыгыз: җырчы кыз Вероника.
3 нче бит.

Яңа елга - яңа әкият.
4 нче бит.

Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!


6 декабрь, 1997 ел.
N 97
(4917)





Балалар һәм яшүсмерләр газетасы





ИЛДӘ НИЛӘР БАР ИКӘН?

ФЕХТОВАНИЕ буенча олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә дөнья, Европа һәм Олимпия уеннары чемпионы Наилә Гыйләҗева призларына Россиянең иң көчле яшь фехтование осталары бәйгесе үтте.

КАЗАННЫҢ "Инга-Арт" антиквар салонында дөньяның 80 иле акчасы тупланган күргәзмә ачылды.

Кыргызстан башкаласында "Татар кухнясы" дигән кафе ачылды.

ӘЛМӘТТӘ шагыйрә С. Сөләймановага һәйкәл ачылды.

КАЗАН ипподромында Президент М.Ш. Шәймиевкә Мари-Эл Президенты бүләк иткән "Торнакай" биясе тайлады.

КОНГОДА тоткын итеп алынган Казан очучылары Татарстанга әйләнеп кайтты.

ТАТАРСТАН Төньяк диңгез флотының тагын бер су асты көймәсен шефка алган. Көймәгә "Казан" дигән исем бирелгән.

КАЗАНДАГЫ 152 нче мәктәпнең 10 нчы сыйныф укучысы Г. Хәмидуллинга Иваново шәһәрендә үткәрелгән "Российские самоцветы" конкурсында 1 дәрәҗә Диплом алып кайтты.

СӘЛАМӘТЛЕК саклау министрлыгы, Балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты 1 декабрьдә СПИДка каршы көрәш көне уңаеннан төрле чаралар уздырды.

ТАТАРСТАН журналистлар берлеге үзенең 40 еллык юбилеен билгеләп үтте.

"Сабантуй" газетасында эшләүче апалар һәм абыйлар!

Без сезнең газетаны бик яратабыз. Андагы мәкаләләрне, хикәя-әкиятләрне, шигырьләрнең барысын да диярлек укып барабыз. Мәктәпкә килгәч, берберебез белән фикер алышабыз. Барыбыз да киләсе ел өчен "Сабантуй"га язылдык инде.

Сезнең газетага уңышлар теләп, Татарстан республикасының Апас районы Югары Ындырчы мәктәбенең III сыйныф укучылары:

Фәнис БАКИРОВ, Альбина ВИЛДАНОВА, Рушан ИХСАНОВ, Регина САЛИЕВА, Резеда САЛИХОВА, Лилия САФИУЛЛИНА.

Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Нәҗибә ИХСАНОВА газетабыз турында менә ниләр әйтте:

БЕЗ иске, ташландык /бәлки иске, ташландык та булмагандыр/ китап битләренә күмер белән беренче хәрефләребезне яздык, язарга өйрәндек. Китаплар, уку-язу әсбаплары булмады. Шуңа күрәдер - ме, балалар, яшьләр өчен булган газета-журналларны ниндидер бер аерым хис, тойгы белән укыйм, яратам. Оныкларымда хәрефкә, кәгазьгә, гомумән, укырга тирән мәхәббәт уятырга тырышам, алай гына да түгел, үзләренең каләм тибрәтүләренә өметләнәсе килә.

"Сабантуй" газетасын кулга алгач иң беренче яшь укучыларыбызның язмаларын, аларның иҗат җимешләрен күреп куанам. Һәмдә бәхетле халкыбыз— аның якты киләчәген күргән кебек булам. Нәҗибә Ихсанова.

ЧИР КИТӘ, ГАДӘТ КИТМИ

ГАЗЕТА-журналлардан иң беренче итеп яраткан газетам "Сабантуй"га язылдым. "Бөтен кеше дә языла, моның нәрсәсе бар?"- диярсез.

1963 нче елдан бирле /"Яшь ленинчы" чагыннан/ алам бу газетаны. Мәкаләләрем дә чыккалый иде. Балачакта мәкалә саен каршы җавап алуы гына ни тора иде: зур зәңгәр конверт. Ә эчендә иң җылы сүзләр...

"Чир китә, гадәт китми", диләр бит. Шушы балалар газетасына язылу гадәте, олыгайгач та китмәде бит.

Хәзер мин аның кирәклегенә елданел ышана барам. "Сабантуй"дан тыш, "Татарстан яшьләре", "Заман", "Шәһри Казан", "Юлдаш" газеталары һәм "Ялкын", "Сабыйга", "Мәгариф" журналлары алсам да, иң беренче сезнең газетаны укырга тотынам.

Илдәге яңалыкларны да иң беренче сезнең газетадан укыйм. "Әнием киңәшләре"н дә сездән кулланам. Гомумән, сезнең газета мәктәп елларына, балачагыма да кайтырга булыша.

"Сабантуй"ны эшемдә дә кулланам. Матур-матур җөмләләрне дә сезнең газетадан эзлибез. Укучылар дәрескә әзерләнгәндә дә, дәрестә дә газетадагы материаллардан файдаланалар. Ә язучылар турында чыккан урта битләрне аерым җыеп барабыз. Аны чыгаручыларга да зур рәхмәт! Хәзерге көндә дәрес материалларына кытлык булганда, ул безгә зур ярдәм булып тора.

Бераз үзебез белән таныштырырга булдым:

Мин 7 нче Г сыйныфының җитәкчесе булып эшлим. Укучыларның төп эше уку булса да, без уку белән генә чикләнмибез. Ялларыбызны һәм буш вакытларыбызны күңелле, файдалы итеп үткәрергә тырышабыз. Әле күптән түгел генә "Лидер-шоу" дигән бәйрәм үткәрдек. Аның өчен һәр сыйныф алдан әзерләнде. I тур стена газетасы һәм радиогазета чыгарып тапшырудан торса, II тур инде бәйрәм формасында узды.

Актлар залы бәйрәмчә бизәлгән иде. Һәр сыйныф үзенең лидерын ничек булдыра ала, шулай күрсәтергә тырышты. Монда сөйләү дә, җыр да, музыкаль күренешләр дә булды.

Бәйрәмнәр үткәргәндә дә, сыйныф һәм татар теле дәресләрендә дә сезнең газетадан файдаланырга тырышабыз. Киләсе ел өчен сыйныфыбыз белән сезнең газетага язылып куйдык инде.

Безгә эшебездә кулланырга һәм күңелле ял итәргә булыша торган газета чыгаруыгыз өчен Сезгә зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Роза ВӘЛИӘХМӘТОВА. 111 нче рус-татар урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

ЧАКЫРУ

Хөрмәтле укучым ________________

"Сабантуй" сезне 9 нчы декабрь көнне 14 сәгатьтә Тукай музеена (Тукай урамы, 74) редакциябез хезмәткәрләре һәм газетабызның якын дуслары белән очрашуга чакыра.

Рәхим итегез!

Белешмәләр өчен телефон: 49-36-92.



ЯҢА МӘКТӘПТӘ - БЕРЕНЧЕ БӘЙРӘМ



Яңа мәктәп дигәннән, әй көттеләр дә бит ул яңа мәктәпне Азино балалары. Бер атна, ике, өч, бер ай, ниһаять, ай ярым дигәндә, Казанның гүзәл бер почмагында мәһабәт бина калкып чыкты. Азино - 1 бистәсендә яшәүче малайлар, кызлар укыячак 161 нче мәктәп иде ул.

Әлеге күркәм бинада дәресләр дә матур гына башланып китте. Бәйрәмнәр дә, викториналар да... "Бәхетле очрак" викторинасы шуның ачык бер мисалы.

V Б белән V В классы укучылары көч сынашты ул көнне. Әдәбиятка, спортка, тарихка, табигатькә кагылышлы белемнәрен күрсәттеләр.

Елда күпме ай бар? Аю кышкы йокыга талганда ябык буламы, сизмезме? Көздән соң елның кайсы фасылы килә? Футбол матчы ничә минут дәвам итә?

Ә-ә, дусларым, сезнең дә җавабыгыз әзерме?! Бик яхшы. Димәк, V Б сыйныфы укучылары белән беррәттән сезне дә җиңүче дип билгеләргә була. Тик менә бишенчеләрнең класс җитәкчеләре Елена Викторовна Фәтхуллина белән Люция Шамил кызы Гыйниятуллиналар бүләк иткән чәерләр, шоколадлар гына сезгә эләкмәс. Хәер, борчылырга урын юк. Сезнең мәктәпләрдә дә еш була бит андый бәйрәмнәр - викториналар. Димәк, шоколад ашар көннәрегез алда әле.

Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА.

Рәсемнәрдә: "Бәхетле очрак"тан күренешләр.

Автор фоторәсемнәре.





ТЕЛНЕ ЙОТАРЛЫК ТӘМЛЕ СӨТ, КАЙМАК, ЭРЕМЧЕК

Татарстан Педагогия җәмгыяте идарәсе аеруча актив, иҗади эшләүче укытучылар өчен ике атнага сузылган экскурсия оештырды. Аңа мин дә катнаштым. Маршрутның соңгы пункты Эстония булды. Нарва шәһәрендә кунак йортында яшәп, көннәр буе республиканың төрле шәһәрләрендә, авыл җирләрендә булдык, халык мәгарифе эшләре белән таныштык. Таллин, Тарту, Ивангород шәһәрләрен күрдек. Эстония элекке СССРга керә торган иң кечкенә союздаш республика иде. Эстоннар бервакытта да урыс империясе - СССР составында булулары белән ризалашмадылар. Бүген Эстония республикасы - чын мәгънәсендә бәйсез дәүләт. Экскурсия вакытында шулар күзгә ташланды: һәр җирдә киң, чиста асфальт юллар. Алдагы авыл, шәһәрнең тулы исеме язылган, ничә километр җир үтәсе күрсәтелгән. Без утырып йөргән автобусның эче шулкадәр чиста - аяк киеме белән үтәргә оят кебек тоела. Автобусны ике шофер йөртә. Берсе - кабинада, руль артында, икенчесе - салонның алгы бер урынында ял итеп утыра. Икесе дә ак күлмәктән, галстуктан. Сәгать саен алмашалар. Көн буена радио сөйләп тора. Тапшырулар эстон телендә генә. Урамнарда, биналарда - лозунгларда, политбюро әгъзаларының (Компартия җитәкчеләренең) рәсемнәре дә юк...

Шуны да белдем-күрдем: кибетләрдә урысча мөрәҗәгать итүчеләрне яратмыйлар, урысчаны аңламаганга салыналар. Шуны белеп мин бер сатучыга татарча мөрәҗәгать иттем, аласы килгән әйберемне кулым белән төртеп күрсәттем. Әлбәттә, сатучы минем татар икәнемне белмәгәндер, әмма ул елмаеп, миңа сораган әйберне алып бирде. Халык аз сөйләшә, үзен тыйнак тота дигән тәэсир калды. Тагын шуны әйтәсем килә: республиканың кайсы почмагында булма, ашханәдә безне әле иртән генә савылган тәмле сөт, бүген генә әзерләнгән каймак, эремчек "көтеп тора иде". Яшелчә ашлары да шундый.

Экскурсияләр программасы үтәлгәч, безне автобус белән Ленинградка (хәзерге Санкт-Петербург) алып киттеләр. Эстония чиген үтеп чыгуыбыз булды, бөтенләй башка дөнья башланды:мескен өйләр, җимерек каралтылар. Юл буенда исерекләр ята. Кемдер көлеп: "Матушка Россия начинается",- диде. Ниһаять,Ленинградка килеп кердек. Җитәкчебез безне ашату хәстәрен күрә башлады. Әмма ашханә хуҗалары бездән баш тарта, берьюлы 100 кешене утырта, ашата алмыйбыз, диләр.

Шулай да бераздан бер миһербанлысы табылды. Ашханәнең идәне чиста булмаса да, үпкәләмәдек. Моңа без күнгән инч... Өстәлгә карабодай боткасы, авызга капмаслык тозлы, искергән ит кисәге, юынтыкны хәтерләткән бер стакан чәй китереп куйдылар. Ботка тазартылмаган ярмадан пешерелсә дә, мондый хәлгә үзебездә күнеккәнгә күрә, эндәшмәдек. Нишлисең, илең нинди - ашың да шундый, дип күңелне тынычландырырга тырыштык.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.



ӘЛЕ ДӘ ИСЕМДӘ:

ҖӘЙНЕҢ кояшлы, ямьле бер көне. Кошлар сайрый, агачларда кызарып алма пешә... Шундый күңелле көндә дәү әнием моңсу. Ул Азат абыйдан - улыннан хат көтә. Улы армиядә. Менә хат ташучы апа да килеп җитте. Ул дәү әнигә гәҗит сузды. Дәү әни: "Миңа хат юкмы, кызым?"- дип сорады. "Юк шул", - диде хат ташучы апа. Менә шушы вакытта алар янында басып торган әтәч белән тавык ничектер моңсулы тавыш белән кычкырып җибәрделәр. Әйтерсең лә, алар да аңлыйлар һәм борчылалар иде. Дәү әнинең хат алырмын дигән бүгенге өмете дә өзелде. Мин аны бик тә кызгандым: ул төннәр буе йокламыйча балалар үстергән, шуңа карамастан, безгә йомшак оекбашлар, бияләйләр бәйли. Үзенең күзе дә күрми бит әле, тавыклар, үрдәкләр, каз бәбкәләре, терлекләр асрый. Менә шушы картайган көнендә да шатланып яши алмый, армиядәге улы өчен борчыла, исән-сау микән, дип йокысыз төннәр уздыра. Балаларга теләгем шул: әниләрен онытмасыннар иде!

Лилия ДАУТОВА.
Казан, 71 нче гимназия.

«Каләмдәш» клубы

ҖЫРЧЫЛАР БӘЙРӘМЕ

КАЗАН шәһәренең Ш. Мәрҗани исемендәге татар гимназиясендә халкыбыз тарихына, аның гадәт-йолаларына багышланган кичәләр, очрашулар еш булып тора.

Күптән түгел генә булып узган "Татар халык җырлары" фестивале укучылар күңелендә бик озак сакланыр. Һәр класс аңа бик тырышып әзерләнде, халкыбызның йөзек кашы булырдай җырларын өйрәнде.

Кичәбезгә кунак булып республикабызның халык артистлары Шамил Әхмәтҗанов белән Миңгол Галиев һәм танылып килүче яшь сандугач Альберт Ситдиков килгәннәр иде. Алар яшь җырчылар иҗатына олы бәя бирделәр, укучыларның киләчәктә дә халык җырларын онытмауларын телəделәр. Мондый фестивальләр гимназиябездә ел саен уздырылачак.

Айгөл ГАФИЯТОВА.
Казандагы 2 нче гимназиянең 6 Б сыйныфы укучысы.

* * *

Без катлаулы чорда яшибез, һәр уңыш зур кыенлыклар белән бирелә, ләкин авырлыклар күбрәк булган саен, җиңү шатлыгы да зуррак була, сирәк килгән бәйрәмнең кадере дә арта. Яңа мәктәп бинасы укучылар һәм укытучылар кулына тапшырылган көн дә авылыбыз өчен бәйрәм булды.

Олы Карамалы авылы Татарстанга билгеле, чөнки бу авылда туып-үскән атаклы язучы, Г.Тукай исемендәге Республика дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Газиның әсәрләре барлык әдәбият дәреслекләренә кертелгән. Безнең яңа мәктәбебезгә дә атаклы авылдашыбыз И. Гази исеме бирелде.

Гомумән, безнең авылыбызның мәгърифәт тарихы гаҗәеп тирән. 1879 елда ук авылда дини мәдрәсә ачылган, 1888 елдан бирле мәктәп эшли, ә 1918 елда "I баскыч совет мәктәбе" дип атала башлый. Кайчандыр Ибраһим Гази укыган бу башлангыч мәктәп бинасы күптән юк инде. Мәктәпнең җидееллык булып әверелгәненә дә быел 70 ел тула. Шушы вакыт эчендә Олы Карамалы мәктәбе бинасыннан күпме белемле кешеләр тормышка юл алганнар, алар арасында нинди генә һөнәр ияләре юк! Атаклы драматург, Татарстан Югары Советы депутаты Туфан Миңнуллин үзенә урта белем биргән укытучыларын тирән хөрмәт белән искә ала. Республика спорт комитеты рәисе Х. Мортазин, югары уку йортларында укытучы фән кандидатлары Э.Сәйфуллин, Г.Заһретдинов, З.Рәмиев тә шушы мәктәпне тәмамлаганнар.

Мәктәпнең йөзен укучылар гына түгел, укытучылар да билгели. Татарстанның атказанган укытучысы, Ленин ордены кавалеры, урта мәктәпнең беренче директоры Кадыйр ага Халитовның якты истәлеге алдында без бүген баш иябез. Шулай ук Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Мөхәммәт Әхмәтҗанов, Татарстанның атказанган укытучысы Сөембикә Кәримуллина, РСФСРның Мәгариф отличниклары Мәсгудә Беляева, Җиһан апа Әхмәтҗановаларның тырыш хезмәте дә иң олы мактауга лаек.

Олы Карамалы урта мәктәбенең яңа бинасы авылның иң югары урамына төзелде. Ул үзенең данлы традицияләрен дәвам итеп, киләчәктә дә авылга белем нурлары сибеп торучы, чын мәгънәсендә мәгърифәт учагы булып яшәр.

Эльвира МИФТАХОВА.
Кама Тамагы. И.Гази исемендәге Олы Карамалы урта мәктәбе.




ӘЙДӘГЕЗ, СУМКА ТЕГӘБЕЗ

АНЫ калын, нык тукымадан тексәгез, әйбәтрәк булыр. Әгәр тукыма бер төсле генә булса,төрле төстәге тасмалар белән бизәргә дә була.

Төбен ясалма күннән ясагыз. Кирәкле детальләрне кисеп, төбенә тегеп тә куегыз. Юкарак тукымадан эчлек-капчык тегегез. Аны да төбенә беркетеп куегыз. Сумканың өстен ясалма күннән кисеп ясалган чуклар белән бизәргә дә була.

Ә хәзер эшнең иң авыр өлеше: сумканың өске әйләнәсенә пөхтә итеп 8 кечкенә тишек тишеп, читен типчеп чыгыгыз. Шушы хасил булган тишекләр аша матур калын бау /шнур/ үткәрегез. Ул сумкагызның тоткычы булыр. Бу сумка белән сәяхәткә чыгарга, бакчага, кибеткә, я пляжга барырга бик уңай булыр.





ҖЫРЧЫ КЫЗ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

ВЕРОНИКА сәнгать сөючеләргә халык шагыйре Илдар Юзеевның "Гашыйклар тавы" әсәрендәге җыры белән танылды. Башына киң кырлы салам эшләпә киеп, кулына кәрзин тотып:

"Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч сүзсез калдым.
Адаштым дип алдаштым."- дип матур итеп җырлады ул.

Вероника тәүге тапкыр сәхнәгә биш яшендә чыга. Чаллыдагы 26 нчы мәктәп-гимназиядә ул гади класста түгел, ә театр сәнгате классында белем ала. Аның белән бергә бу класста 36 малай һәм кыз да укый. Мәктәптәге Яңа ел, 8 Март, Укытучылар көне бәйрәмнәрен гел алар оештыра.

Вероника шәһәрнең "Остабикә" ансамбленә дә йөри. Анда онытылган милли гореф-гадәтләребезне, җыр-уеннарыбызны табып, аларны яңадан сәхнәгә чыгаруда, халыкка танытуда катнаша. Вероника Еремина, бу ансамбльдән башка, тагын әле КамАЗ мәдәният сараеның "Айгөл" ансамбленә дә йөри. Ул анда рус халык такмакларын, шаян җырларын, башкорт җырларын башкара.

Каникулларын Вероника гадәттә дәү әниләрендә, Биектау районының Чыпчык авылында уздыра. Катя әбисе оныгына аш-су әзерләү серләрен өйрәтә. Иң яраткан азыгы - мантый икән. Авылдагы малайлар-кызлар белән табигать кочагында ял итә. Ләкин бераздан яңадан Чаллыга кайтасы килә башлый. Ак шәһәрне, үзләре яшәгән Хәсән Туфан урамын, дусларын, апасы Ларисаны, әнисен сагына...

Әнисе Әнүзә ханым - Чаллының "Шатлык" яшьләр үзәге директоры. Соңгы концертларында Вероника әнисе язган җырларны башкарды. Казанның Химиклар мәдәният сараенда булган "Вероника һәм Йолдызлы фейерверк" дигән күңелле, шаушулы тамашаны да ул әнисенең "Иа, ходаем!"дигән җыры белән ачып җибәрде. Концертта ул егермедән артык җыр башкарды. Һәм шул кадәр үк күлмәк, туфли алыштырды/!/ ТР атказанган мәдәният эшлеклесе Алия Хафизуллина җитәкләгән "Айгөл" ансамбле кызлары да бик матур киемнәрдән иде. Вероникага һәм бу ансамбльгә Чаллы шәһәре мэры Р. Алтынбаев матди ярдәм күрсәтә икән. Аяк киемнәрен махсус алар өчен "Агат" аяк киеме фабрикасы осталары җитештергән, ә күлмәкләрне "Тобиус" мода үзәге теккән.

Вероника үзен бик бәхетле дип саный. Ләкин аның әлегә тормышка ашмаган бер хыялы бар. Ул - танылган җырчыларның тавышы яңгыраган Италиягә барып үзен таныту. Шуңа да итальян малае Робертиноның "Джамайка"сын үз репертуарына керткән инде. Вероника үз җырларын татар, башкорт,төрек, итальян, инглиз, француз һәм рус телләрендә башкара. Ул Татарстан һәм регион күләмендә уздырылган бәйгеләрдә, фестивальләрдә дүрт тапкыр лауреат исемен яулаган, Төркиядәге җыр фестивалендә дипломант булган, Болгариядә халыкара фестивальдә лауреат исемен яулаган. Мәскәүдә уздырылган ОРТ телешоуларында катнашкан, "Сандугач" фестиваленең гүзәле" исемен яулаган. Аның җырлавын Анапа һәм Туапсе шәһәрләрендә дә ишеттеләр. Вероникаsuccessfully һәм "Айгөл" ансамблен Казанга алып килгән зур автобусның биленә:

"Халыкның бер йорты бар,
Ул да булса - Туган ил.
Алтын-көмеш яуган җирдән
Туган үскән ил артык", - дигән



акыллы сүзләр язылган. Казандагы концертларын карагач, бу сүзләр яшь артистларның тормыш девизы икәнен аңладым мин.

Фәридә ВАГЫЙЗОВА.



Я, әйтегез, кайсыгыз әкият яратмый, геройларының мажаралары белән кызыксынмый? Балалар бакчасына йөргән вакытта, мәктәптә укыганда курчак театры спектакльләрен карамаган бала, мөгаен, юктыр. Башкалабызның бердәнбер Казан дәүләт курчак театры октябрьнең соңгы көннәрендә үзенең яңа, 64 нче сезонын башлап җибәрде. Нәни дуслары янына йөрүдән, уку елында гына түгел, җәйге каникул көннәрендә дә туктап тормый курчак уйнатучылар. Ә репертуарлары шактый бай - татар һәм рус телендә 29 спектакль.

- Һәр елны өр-яңа 4-5 спектакль чыгарабыз,- ди театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус Зиннуров.

Быелгы сезонны да театр яңа спектакльләр, ягъни премьералар белән ачып җибәрде. Шарль Перроның" "Итекле мәче" әкиятен белмәгән бала юктыр. Драматург Мансур Гыйләҗев һәм театр режиссеры Людмила Дьяченко әлеге әкиятне сәхнәләштереп балаларга тәкъдим иттеләр. Бу көннәрдә нәни тамашачылар урыс драматургы А. Соллогубның"Беда от нежного сердца" водевилен дә күрде инде. Татар халык әкиятләренә нигезләнеп Р. Корбан һәм З. Думави "Ак күлмәктә кара елан" исемле пьеса язганнар. Җәй көне премьерасы булган әлеге спектакль бу сезонда да үз тамашачысын табар әле.

Театр яңа дусларын тагын өр-яңа әкиятләре белән дә шатландырырга уйлый. Декабрь аенда Илдус Зиннуров тәрҗемә иткән "Котбетдин мажаралары"н да сезнең хөкемгә җиткерергә әзерләнәләр. Балалар, әлбәттә, Кыш бабай һәм Кар кызы белән бергә Яңа ел чыршысы янындагы тамашаларда да катнашырсыз әле.

Нәни дусларым, "Мәче, әтәч һәм төлке" дигән урыс халык әкиятен укыганыгыз яки ишеткәнегез бардыр. Т. Миңнуллинның Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары уйнаган "Авыл эте Акбай"ны да , бәлки, карагансыздыр. Ә җәйгә таба әлеге әкиятләрне сезгә курчаклар уйнап күрсәтәчәк.

Дуслар, Казан дәүләт курчак театрында сезне әнә никадәр мавыктыргыч, кызыклы әкиятләр көтә икән. Ә сез фоторәсемдә күргән "Ак күлмәктә кара елан" әкиятендә хәтта кара еланнар да елмая...

Л. ФӘСХЕТДИНОВА.

А. ТӘХАВИЕВ фоторәсемнәре.











УЛ БАРМАКТА - ҖИДЕ ҖАНВАР

Ә хәзер, кадерле укучылар, сезне тагын бер театрга чакырабыз. Әйе-әйе, ялгыш укымадыгыз, чып-чын театрга алып барабыз сезне. Ләкин сәхнәдә актерлар урынына гап-гади... куллар уйнар. Хәзер үзегез дә аңлап алгансыздыр инде: сезнең алда куллар театры тамашасы булачак. Дөньяда андый театр чынлап та бар. Ул Мәскәүдә, Марионеткалар театры бинасында - Петровские линии, 1/20 адресы белән урнашкан (Кузнецк күпере метро станциясе белән янәшә).Сезгә тәкъдим ителгән рәсемнәрнең һәркайсын игътибар белән карагыз әле, анда кайсы җанвар сурәте? Нәрсә, аптырашта калдырдымы әллә? Алайса кулларыгызны рәсемнәрдәгечә куеп, стенадагы шәүләгә карагыз, ягез, кайсы җанварларны таныдыгыз? Җавапларыгызны 22 декабрьгә чаклы редакциягә җибәрегез. Җиде сурәтне дә дөрес таныган биш укучыны истәлекле бүләк көтә.













МӘКТӘПТӘ беренче ярдәм күрсәтү алымнарын өйрәнәләр.
-Сәлим, әгәр энең ачкыч йотса, нишләр идең?
- Өйгә тәрәзәдән керер идем...

* * *

Марат:
- Әтием әйтә, алуга караганда, бирү яхшырак, - ди.
- Ул синең мулламы әллә?
- Юк, ул боксчы.

* * *

Физика дәресендә:
- Электр тогын ышку юлы белән дә алып була. Мәсәлән, һәркайсыгызның мәчене йонына каршы сыпырганы бар. Ул чакта электр очкыннары чыга...
- Ә электр станциясе эшләсен өчен ничә мәчене сыпырырга кирәк?

* * *

Очучылар мәктәбендә укучы курсант беренче тапкыр очыш дәресенә килә. Инструктор белән янәшә утыра да, күзен йомып, ул әйткән хәрәкәтләрне үти башлый. Аннан күзен ачып, аска карый да:
- Карагыз әле, аста кешеләр бигрәк кечкенә, нәкъ кырмыскалар кебек...
- Бу чынлап та кырмыскалар, без бит әле күккә күтәрелмәдек, - ди инструктор.





КАРАГАН САЕН ҖАНЛАНА

1975 елның көзендә без Латвиядә - язучыларның Дубылты иҗат йортында булдык. Хөрмәтле аксакалларыбыз Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйриләр белән ай буе бергә аралашып яшәү, иҗат итү онытылмас көннәр булып калды. Хәсән абыйга багышлап 1988 елда "Истә синең якты гомерең..." дигән истәлекләрем гәзитебездә дөнья күргән иде. Күп кенә язучыларның хатирәләрен туплап, Татарстан китап нәшрияты Хәсән Туфан турында күләмле китап та чыгарды. Истәлекләремдә әлеге фоторәсем турында да язган идем.

"Иҗат йортыннан китәр алдыннан бергәләп фоторәсемгә төштек. Шаярышып-көлешеп сөйләшкәндә туктап калган ул мизгел караган саен җанлана да китә... Менә без бүлмәләргә таралышабыз. Хәсән абый да язу өстәлендәге гарәпчә шигырь теркәлгән тар-тар кәгазьләр өстенә иелә, пөхтәләп кенә яза башлый... Балтик буенда бүтәннәр гәрәбә эзләп киләп сарып йөргәндә дә, пәрдәләрне корып, ут яктысында эзләгәне үзгә аның. Күңел диңгезеннән хис дулкыннары каккан уй-тойгыларын шигъри-мүенсаларга сак кына тезә..."

1900 елның 9 декабрендә туган Хәсән Туфан. Үзе исән чакта без аны котлый идек. Рухы шат булсын, яраткан шагыйребезне - Такташ, Җәлил, Хәкимнәрнең дустын тагын бер кат искә алыйк әле, шигырьләрен, җырларын искә төшерик. Хөрмәтлебез Гомәр ага Бәшировка имин гомерләр, иҗат уңышлары телик.

Шәүкәт ГАЛИЕВ,
Хәсән Туфанның әдәби мирас комиссиясе рәисе.

Рәсемдә: Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Шәүкәт Галиев, Хәсән Хәйри. 1975 елның 17 октябре. Латвия.

Гәрәй РӘХИМ
Ризван ХӘМИД



(Яңа ел бәйрәме күренешләре)

Катнашалар:

КЫШ БАБАЙ
ЯҢА ЕЛ - Кыш бабайның варисы
НӘҮРҮЗ БАБАЙ - милли Яңа ел
НӘҮРҮЗБӘК - Нәүрүз бабайның варисы
ЗӨҺРӘ - Айда яшәүче кыз

КАЛАБАШЫ
ҖИР ИЯСЕ
ҺАВА ИЯСЕ
УТ ИЯСЕ
СУ АНАСЫ
- Калабашының яраннары, мифик көчләр

СУСЫЛУ - Су анасының оныгы
ШОМБАЙ - заман кәсәбәчесе, товар рекламалаучы

Куючылар өчен искәрмә. НӘҮРҮЗ БАБАЙның Чыршы бәйрәменә катнашуы гаҗәпләндермәскә тиеш: чөнки ул, милли календаребез буенча мартта башланган Яңа ел символы булса да, шактый күп еллар Нардуган белән бергә декабрь азакларында искә алына килгән, бары тик соңгы елларда гына ул үзенең кануни урынына кайтты. Икенчедән, КЫШ БАБАЙ бездә кунакта салкын кышта гына, ягъни, 1 гыйнварда гына булса да, НӘҮРҮЗ БАБАЙ - турыдан-туры Кояш белән бәйләнгән мифик зат, ел тәүлегенең теләсә кайсы чорында да күренә ала.

Тигез мәйдан: ул кар каплаган урман аланы да, өстенә боз каткан күлгә яки киң елгага да охшаган. Кич, әмма бик якты, чөнки күктә тулган Ай балкый: анда көянтә-чиләк күтәргән ЗӨҺРӘнең шәүләсен күрергә мөмкин. Нәкъ мәйдан уртасында Айның көмеш нурларында мәңге яшел биек Чыршы коенып тора. Аның югары өлеше бәйрәмчә бизәлгән инде. Чыршыдан берничә адым читтәрәк искиткеч матур бизәкле бәке бурасы.

Менә әкрен генә бәкенең капкачы ачыла һәм анда маңгай чәчләренә алтын тараклар кадаган,өсләренә бака ефәгеннән тегелгән озын күлмәкләр кигән һәм чәчләре аяк тубыкларына чаклы салынып төшкән СУ АНАСЫ белән аның 10-12 яшьлек оныгы СУСЫЛУ пәйда буладыр. СУ АНАСЫ бәке бурасыннан чыга.Алар сагаеп кына тирә-якны карыйлар һәм Чыршыны күрәләр.

СУСЫЛУ. *Дәү әнием! Карале! Нәрсә бу?!*

СУ АНАСЫ. *Җир өстендә яшәүче кешеләр Чыршы дип атыйлар аны...*

СУСЫЛУ. *Ә нишләп аның очын күккә ябыштырылган сары шарга беркеткәннәр?*

СУ АНАСЫ. *Аумасын дип, очын Айга кадаклыйлар аның... Әһә! Чыршыны Яңа ел бәйрәменә бизи башлаганнар икән инде... Димәк, Кыш бабай быел да шушында киләчәк! Бу юлы сакалыннан тотып сөйләшмичә китмим. Сөйләшми генә карасын! Ул салкын айларда гына кар иясе, ә синең дәү әниең - кышларын да, җәйләрен дә Су анасы! Хәзер, карыйк әле, кайларда йөри икән ул бу минутларда?.. /Кул сәгатенә урнаштырылган компьютерен кабыза./ Әһә! Менә кайда икәнсең син...Уфада Калабашында кунакта: аларда Яңа ел бәйрәмен ике сәгать алданрак башлыйлар. Ярый, сүзләрен бүлдермим инде, рәхәтләнеп сөйләшсеннәр, сакалыннан йолкырга монда да җитешермен!*

СУСЫЛУ. *Дәү әнием! Ә нигә син аның сакалын йолкырга телисең?*

СУ АНАСЫ. *Үз вазифаларын тиешенчә үтәми! Бәйрәмнән бәйрәмгә Җир өсте балаларына бүләк өләшеп йөрүен генә белә. Ә алар арасында төрлеләре бар. Әниеңнең алтын тарагын кем урлап качкандыр дисең? Җир өстендә яшәүче бер юньсез малай! Кем аркасында үткән җәйдә синең аякларың пыялага киселгән иде? Икенче бер әшәке малайлары яр башыннан буш шешә ыргытып уйнаган иде чөнки! Кем кышларын бәкегә шартлаткычлар ташлап, синең дус балыкларыңны үтерә, йокыга чумган балыкларны куркытып уята? Шундый ук тәртипсез малайлар-кызлар. Кемнәр кара җир мае агызып чиста суларыбызны агулый? Шуларның ваемсыз ата-аналары ! Ә Кыш бабайга барыбер: балаларның тәртипләренә дә, тәртипсезләренә дә бер үк төрле бүләкләр биреп йөри!*

ШОМБАЙ /чыршы артыннан килеп чыга: кулына зур савыт белән чит ил товарлары тоткан/. *Хәерле кич, гүзәл ханымнар - кызлар! Кем "Панасоник" кампитерлары-телевизорлары белән кызыксына, рәхим итегез...*

СУ АНАСЫ /бүлдерә/. *Син кем?! Безне качып тыңлап тордыңмы?*

ШОМБАЙ. *Ялгышасыз, чибәр ханым: Шомбай беркайчан да качып-посып кеше сүзен тыңлап йөрми... Таныш булыйк: мин - хәзерге заман кәсәбәчесе, чит ил товарларын рекламалаучы Шомбай булам... Гафу итегез, сезнең үзегезне кайдадыр күргән дә кебек... Ба! Кемне күрәм! Су анасы ич сез! Ә икенчегезне менә танымыйм...*

СУ АНАСЫ. *Танымассың да!* /Кинәт уң кулын селтәп җибәрә: кулы очыннан ниндидер елык-елык килеп орган тузан бөркелгәндәй була һәм шул ук секундта Шомбай, торраташка әйләнеп, карга ава./

СУСЫЛУ. *Дәү әнием! Нигә торраташка әйләндердең аны?! Шундый кызык кеше ич ул!*

СУ АНАСЫ. *Берничә минутка гына ташка әйләндердем мин аны... Безнең серне тыңлап тормасын!*

СУСЫЛУ. *Тиз генә бәкедән чыгып, Чыршының яшел ылысларын тотып-тотып карыйм әле, дәү әнием? Каты микән, йомшак микән?*

СУ АНАСЫ /куркып/. *Чү-чү, бәбкәм! Тәпиләреңне суыбыздан аера күрмә: шундук торрабозга әверелерсең!*

СУСЫЛУ. *Ә нәрсә ул - торрабыз?*

СУ АНАСЫ. *Менә бу адәм актыгы торраташка әйләнде ич...* /Шомбай егылган җиргә карый: аннан җилләр искән!/ *Ә кайда ул?! Кай арада үкчәләрен ялтыратырга өлгергән?.. Тылсым көчем кими башлаган микәнни?!*

СУСЫЛУ. *Син картайдың инде, дәү әни! Пенсиягә чыгарга вакыт. Җир өстендә яшәүче кешеләр шикелле!* /Көлә/ *Торрабызның нәрсә икәнен әйтеп бетермәдең, дәү әнием?*

СУ АНАСЫ. *Чынлап та олыгаеп барам бугай шул, бәбкәм... Син - судан яралган сылу, шуңа күрә син боз булып катасың... Менә шул - торрабыз була инде. Үлем дигән сүз ул синең өчен.*

СУСЫЛУ. *Мине юри куркытасың, дәү әнием! Җир өсте балалары белән дуслашмасын, дисең! Ә нишләп соң, алай булгач, үзең торрабызга әверелмисең, ә? Бер җиреңдә суга тиеп тормый ич! Әһә, хәйләңне тоттыммы, дәү әнием!*

/Кулларын чәбәкләп көлә./

СУ АНАСЫ. *Мин тылсымын беләм аның, бәбкәм.*

СУСЫЛУ. *Дәү әнием, дәү әнием! Мине дә өйрәт әле?*

СУ АНАСЫ /шикләнеп/. *Ә нигә кирәк ул сиңа?*

СУСЫЛУ. *Минем дә, җир өсте малайлары-кызлары шикелле, шушы Чыршы бәйрәмендә буласым килә!*

СУ АНАСЫ /үзалдына/. *Шуннан куркам да шул... Берәр юньсезе алтын тарагыңны талап алып калса?*

СУСЫЛУ. *Ә мин... Ә мин җир кызлары төсле чәчләремне кистереп ташлыйм!* /Кулларын чәбәкли./

СУ АНАСЫ. *Юкны сөйләмә! Син - киләчәктә Су анасы буласы бала. Безгә кыска чәч белән йөрергә ярамый. Койрыгы өзелгән тавыкмыни син? Чыршы бәйрәме турында оныт! Усал этләрдән талатуларны телисеңме?! Әшәке малайлар белән җир өсте тулы хәзер.*

СУСЫЛУ /елардай булып/. *Ә минем Кыш бабайны якыннан күрәсем килә... Ул гел аларның Яңа ел бәйрәменә килә, ә безнең янга беркайчан да төшкәне юк.*

СУ АНАСЫ /оныкасының чәчләрен сыйпый/. *Дәү әниеңнең дә якыннан күргәне юк аны...* /Кинәт/ *Телисеңме, бәбкәм, мин аны бүген үзебезгә урлап алып китәм?*

Баш мөхәррир
Ләлә ГЫЙМАДИЕВА

ШЕФ-МӨХӘРРИР
РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН

Редколлегия:
Шәүкәт ГАЛИЕВ
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ
Ләбибә ИХСАНОВА
Равил РАХМАНИ
Семен ФЕДОРОВ
Солтан ШӘМСИ
Илдар ЮЗЕЕВ

Редакциянең иҗади коллективы:
Рузилә МӨХӘММӘТОВА (җаваплы секретарь)
Айдар ГЫЙМАДИЕВ
Фәридә ВАГЫЙЗОВА
Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА
Ләлә ФӘСХЕТДИНОВА
Светлана ПРИВИНА
Альберт ТӘХАВИЕВ

Редакциянең техник хезмәткәрләре:
Фирая МАЛИКОВА
Илгизә САДРИЕВА
Тәнзилә ӘХМӘТОВА
Баш бухгалтер:
Әминә ГАРИПОВА



"Сабантуй"ны оештыручылар- Татарстанның Мәгариф министрлыгы, Яшьләр оешмалары Советы, Балалар Фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы.

1924-90 елларда "Яшь ленинчы" исеме белән чыкты.

Индексы-54124.

Тираж13200. Адрес:420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.



Телефоннар:
49-36-86,49-36-90,
49-36-92,49-36-88,
49-36-94,49-36-95.

Ярдәм итәргә теләсәгез:
р/счет 2345716/700161998
в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г.Казани БИК 049205798
ИНН 1657005818
"Для фонда редакции"

Газета ТР Матбугат һәм информация министрлыгында теркәлгән
Теркәү таныклыгының номеры 451



Татарстан газета - журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.
Заказ 2324
Басарга кул куелды: 1997 ел, 3 декабрь, 15 сәгать.